ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 июня 2023 г. № 4670

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4418 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муницаиль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4418 номерлы карары (Башкарма комитетның 2022 елның 24 июнендәге 3192 номерлы карары редакциясендә) белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муницаиль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләнгән экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.»;

3) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.8 пункт өстәргә:

«3.8. Гомуми билгеләре буенча, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә мөнәсәбәтле рәвештә берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү.

Муниципаль хезмәт гариза бирүченең категориясенә һәм мөрәҗәгатьнең нигезенә бәйсез рәвештә күрсәтелә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан

Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов